КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 сентябрь г.Казань № 773

Архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт милкенә караган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану өчен муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләмен исәпләп чыгару өчен 2021 – 2023 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын 12,04 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 716 нчы карары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин